**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 1 Кәрәкәшле ав. 2020 елның 21 гыйнвары**

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 20.11. 2014 ел №21 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ**:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 20.11.2014 ел, № 21 карарына (27.04.2015 ел, №11, 22.05.2015 ел, № 13, 15.10.2015 ел, №8 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 2 статьяның 1 пунктында "Салым ставкалары" пунктында:

1) 2 абзацны төшереп калдырырга;

2) 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җирләргә, шулай ук "Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып барулары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата - 0,15%;

3) 5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Торак фонды һәм торак - коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары урнашкан җирләргә карата - 0,25% (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына кермәгән объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктан тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);

4) 6 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җирләргә карата - 0,25%».

2. Хисап чоры, салым һәм аванс түләү тәртибе һәм сроклары.

2.1. Салым түләүчеләр өчен хисап чоры дип календарь елының беренче, икенче һәм өченче кварталлары танылуын билгеләргә.

2.2. Салым буенча салым һәм аванс түләүләренең түбәндәге тәртибен һәм срокларын билгеләргә:

2.2.1. Салым түләүче оешмалар өчен салым чоры тәмамланганнан соң түләнергә тиешле салым суммасы, узган салым чорыннан соң килгән елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

2.2.2. Хисап чоры квартал буларак билгеләнгән салым түләүчеләр агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталларыннан соң, җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең дүртенче ставкасыннан берсе буларак салым буенча аванс түләүләрен исәплиләр.

2.2.3. Салым түләүче физик затлар өчен салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.

2. 2.4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 20.11.2014 ел, №21 карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 29 ноябрь, 21 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://jutaza.tatarstan.ru муниципаль районның рәсми сайтында, һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, ләкин рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган чорда һәм җир салымы буенча чираттагы салым чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган вакыт аралыгында үз көченә керә.

5. Әлеге Карарның 2 пункты 2.2.1 һәм 2.2.3. пунктчалары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

**Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы Г.М. Хәмидуллина**